| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БЕГИШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БИГЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**19.07.2018 ел** **№ 12**

**Зәй муниципаль районының Бигеш авыл җирлеге бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр, Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары, Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары тарафыннан эчке финанс контроле һәм эчке финанс аудитын гамәлгә ашыру кагыйдәләрен раслау турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.2-1 статьясы, Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге Уставы нигезендә

## карар бирәм:

1. Зәй муниципаль районының Бигеш авыл җирлеге бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр, Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары, Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары тарафыннан эчке финанс контроле һәм эчке финанс аудитын гамәлгә ашыру кагыйдәләрен расларга.

2. «Зәй муниципаль районының Бигеш авыл җирлеге бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр, Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары, Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары тарафыннан эчке финанс контроле һәм эчке финанс аудитын гамәлгә ашыру кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 25

августындагы 23 номерлы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Бигеш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Бигеш авыл җирлегенең рәсми сайтында (http://zainsk.tatarstan.ru/rus/begishevskoe.htm)) урнаштырырга.

4. Карар аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **И.Р.Вәлиев**

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Бигеш авыл җирлеге
башкарма комитетының
2018 елның 19 июлендәге
12 номерлы карарына
кушымта

**Эчке финанс контролен һәм эчке финанс аудитын гамәлгә ашыру**
**ТӘРТИБЕ**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге тәртип Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге башкарма комитетында (алга таба – җирлек) эчке финанс контролен һәм эчке финанс аудитын оештыруга һәм уздыруга таләпләрне билгели.

1.2. Әлеге тәртипнең максаты булып тора:

- җирлек бюджеты акчаларыннан максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны бәяләү;
- бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылыкның дөреслеген раслау, шул исәптән муниципаль программаларны гамәлгә ашыру турында;
- бюджет законнарының һәм бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган башка норматив актларның үтәлешен бәяләү.

1.3. Эчке финанс контроле һәм эчке финанс аудиты җирлекнең (алга таба - комиссия) вазыйфаи затлары тарафыннан, бюджет чараларын баш бүлүчеләргә (алучыларга) һәм аларга буйсынучы җирлек бюджеты акчаларын алучыларга, җирлек бюджеты керемнәре администраторларына, җирлек бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары администраторларына карата гамәлгә ашырыла.

2. Аудитның эчке муниципаль финанс контроле объектлары

2.1. Эчке муниципаль финанс контроле һәм эчке финанс аудиты объектлары (алга таба-контроль (аудит) объектлары) булып торалар:

- җирлек башкарма комитеты, бюджет акчаларын баш бүлүче (алучы), бюджет керемнәренең баш администраторы, җирлек бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторы, шулай ук җитәкче һәм хезмәткәрләр.

3. Эчке финанс контролен һәм эчке финанс аудитын оештыру

3.1. Эчке финанс контролен һәм эчке финанс аудитын гамәлгә ашырганда тикшерүләр, ревизияләр, карау уздырыла (алга таба - контроль чаралар):

- аерым финанс һәм хуҗалык операцияләренең законлылыгын документаль һәм фактик өйрәнү буенча контроль гамәлләр кылуны, билгеле бер чорга контроль объекты эшчәнлегенә карата бюджет (бухгалтерлык) исәбе һәм бюджет (бухгалтерлык) хисаплылыгының дөреслеген тикшерү;
- тикшерү объекты эшчәнлеген комплекслы тикшерү аңлана торган ревизия, ул кылынган финанс һәм хуҗалык операцияләренең барлык җыелмасының законлылыгын документаль һәм фактта өйрәнү, аларны бюджет

(бухгалтерия) хисаплылыгында чагылдыруның дөреслеге һәм төгәллеге буенча контроль гамәлләр башкаруда чагыла;
-тикшерү дигәндә контроль объектының билгеле бер эшчәнлек өлкәсе торышына анализ һәм бәя бирү күздә тотыла.
3.2.Эчке муниципаль финанс контролен (аудитын) гамәлгә ашыру буенча контроль чаралар расланган план нигезендә үткәрелә.
3.3.Эчке муниципаль финанс тикшерүе (аудит) чараларын планлаштыру элегрәкүткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләрен исәпкә алып, беренчел документларны,бухгалтерлык исәбе регистрларын, норматив документларны, планлы, хисапмәгълүматларын, бюджет законнарын, бюджет акчаларын максатсыз һәм (яки) нәтиҗәсез куллануны, бухгалтерлык (бюджет) исәбенең һәм хисаплылыкның дөрес булмавы турында фаразларга мөмкинлек бирә торган бүтән төр мәгълүматларны өйрәнү юлы белән, шулай ук, елына бер тапкырдан да ким булмаган вакыт эчендә контрольлекне исәпкә алып гамәлгә ашырыла.
3.4. Кирәк булганда, планнан тыш контроль чаралар үткәрелергә мөмкин.
3.5.Тикшерүләрнең еллык планы, агымдагы финанс елында контроль-хисап органы һәм аудит объектларының финанс-хуҗалык эшчәнлегенә карата финанс контроле идарәсе тарафыннан контроль чаралар үткәрүне исәпкә алып, җаваплы зат тарафыннан эшләнә һәм җирлекнең башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан раслана.
3.6.Планнан тыш тикшерүләр авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе кушуы буенча үткәрелә.
3.7.Планлы һәм планнан тыш тикшерүләр җирлек башлыгы чыгарган күрсәтмә нигезендә үткәрелә, анда түбәндәгеләр күрсәтелә: контроль объектының исеме, тикшерелә торган чор, тикшерү темасы һәм нигезе, эш төркеме составы һәм тикшерү чарасын үткәрү вакытлары.
3.8. Контроль чараны үткәрү турында контроль объектына язмача хәбәр ителә.
3.9.Планнан тыш контроль чаралар контроль объектына язмача хәбәр итмичә уздырыла.
3.10.Эчке финанс контролен оештыруны җайга сала торган нормалар эчке финанс аудитын оештыруга кагыла.
4. Эчке финанс контролен үткәрү
4.1. Җирлекнең башкарма комитеты
а) бюджет акчаларын баш бүлүче буларак, җирлектә түбәндәге максатларга юнәлтелгән эчке финанс контролен гамәлгә ашыра:
- җирлек бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторы буларак, бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча бюджетны төзү һәм үтәү, әлеге җирлек бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторы тарафыннан бюджет хисаплылыгын төзү һәм бюджет исәбен алып бару буенча эчке стандартларны һәм процедураларны үтәүгә юнәлдерелгән эчке финанс контролен гамәлгә ашыра;

- бюджет акчаларыннан файдаланунын экономиялелеген һәм нәтиҗәлелеген арттыру чараларын әзерләү һәм оештыру;
б) җирлек бюджеты керемнәренең баш администраторы буларак, чыгымнар буенча бюджетны төзү һәм үтәү, баш идарәче тарафыннан бюджет хисаплылыгын төзү һәм бюджет исәбен алып бару буенча эчке стандартларны һәм процедураларны үтәүгә юнәлдерелгән эчке финанс контролен гамәлгә ашыра;
в) җирлек бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторы буларак, бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча бюджетны төзү һәм үтәү, әлеге җирлек бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторы тарафыннан бюджет хисаплылыгын төзү һәм бюджет исәбен алып бару буенча эчке стандартларны һәм процедураларны үтәүгә юнәлдерелгән эчке финанс контролен гамәлгә ашыра.
4.2.Тикшерү чарасын үткәрүгә керешеп, тикшерү объектына тикшерү чарасын үткәрү турында күрсәтмә күчермәсе тапшырыла.
4.3.Эшче төркем җитәкчесе һәм әгъзалары хокуклы:
- контроль объектының территориясендә, административ биналарында һәм хезмәтбиналарында булырга;
- үзенең оештыру-техник чараларын, шул исәптән компьютерлар, ноутбуклар,калькуляторлар, телефоннар кертергә, чыгарырга һәм алардан файдаланырга;
- контроль чаралар максатларына ирешү өчен, барлык кирәкле документларныалырга (белешмәләр, язма аңлатмалар һәм башка документлар);
- документларның күчермәләрен кәгазьдә дә, электрон рәвештә дә алырга һәм аларны контроль чара материалларына кушарга;
- автоматлаштырылган системаларның мәгълүмати ресурсларыннан файдаланырга;
- тикшерелә торган мәсьәләләрнең асылы буенча телдән аңлатмалар алырга.

Руководитель и члены рабочей группы вправе:
- находиться на территории, в административных зданиях и служебных помещениях объекта контроля;
- вносить, выносить и пользоваться собственными организационно-техническими средствами, в том числе компьютерами, ноутбуками, калькуляторами, телефонами;
- получать для достижения целей контрольного мероприятия все необходимые документы (справки, письменные пояснения и другие документы);
- получать копии документов, как на бумажном, так и на электронном носителе и приобщать к материалам контрольного мероприятия;
- получать доступ к информационным ресурсам автоматизированных систем;
- получать устные разъяснения по существу проверяемых вопросов.

4.4.Контроль чара барышында түбәндәгеләр буенча контроль гамәлләр үткәрелә:
- исәп регистрларындагы язмаларны беренчел исәп документлары белән чагыштыруюлы белән бюджет (бухгалтер) исәбендә һәм бюджет (бухгалтер) хисабында кылынганфинанс һәм хуҗалык операцияләренең тулы, үз вакытында һәм дөрес чагылдырылуы;
- җирлекнең муниципаль милкендәге товар-матди кыйммәтләрнең, акчалатачараларның һәм кыйммәтле кәгазьләрнең фактта булуы, сакланышы һәм дөреслеге;
- исәп-хисапларның, куелган товарлар күләменең, башкарылган эшләрнең һәм күрсәтелгәнхезмәтләрнең, чыгымнарны һәм финанс нәтиҗәләрен формалаштыру буенчаоперацияләрнең һәм финанс нәтиҗәләренең дөреслеге;
- контроль объектының бюджет (бухгалтер) исәбен һәм бюджет (бухгалтер)хисаплылыгын куюы һәм торышы;
- матди кыйммәтләр һәм акчалар хәрәкәтенә карата, чыгымнарныформалаштыруның дөреслегенә, керемнең тулылыгына, акчаның һәм матдикыйммәтләрнең сакланышына һәм факттагы булуына, башкарылган эшләрнең һәмкүрсәтелгән хезмәтләрнең дөреслегенә карата агымдагы контрольнең булуы һәмторышы;
- расланган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитларынигезендә бюджет акчаларын файдалануның нәтиҗәлелеге, адреслылыгы һәм максатчанхарактеры;
- максатчан билгеләнешле бюджетара субсидияләр, субвенцияләр һәм башкабюджетара трансфертлар, шулай ук башка субсидияләр һәм бюджет инвестицияләреалучыларның аларны биргәндә билгеләнгән шартларын, максатларын һәм тәртибенүтәве;
- бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча керемнәрне һәм түләүләрнепланлаштыру (прогнозлау);
- тикшерү объекты карамагына бүлеп бирелгән бюджет кытлыгын финанслау чыганакларын түләү өчен билгеләнгән ассигнованиеләрне куллануның адреслы һәммаксатчан характеры;
- бюджет сметаларының үтәлеше, агымдагы эшчәнлек, бюджет хисаплылыгы беләнбәйле чыгымнарның нигезле булуы;
- хокук бозуларны бетерү, матди зыянны каплау, алдагы тикшерү чараларынәтиҗәләре буенча гаепле затларны җаваплылыкка тарту буенча контроль (аудит)объекты тарафыннан чаралар күрү.
Контроль чаралар барышында шулай ук персоналның эш вакытында эшурыннарында булуын һәм уку планының дәресләрне үткәрү графигы белән тәңгәл килүентикшереп тору гамәлгә ашырыла.
4.5 Контроль чаралар расланган план нигезендә үткәрелә.
4.6.Тикшерү һәм ревизия нәтиҗәләре акт белән, тикшерүнеке (обследованиене) бәяләмә белән рәсмиләштерелә.
4.7. Акт кереш, тасвирлау һәм йомгаклау өлешләреннән тора.
4.8. Тикшерү яки ревизия акты ике нөсхәдә төзелә һәм тикшерү чарасын гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар тарафыннан имзалана.

4.9. Тикшерү яки ревизия актының бер нөсхәсе контроль оешмасы җитәкчесенең танышу турындагы билгесе белән комиссия рәисендә саклана, икенчесе, законнар нигезендә карарлар кабул итү һәм карау өчен, администрация башлыгына җибәрелә.

4.10.Акт нигезләмәләре белән килешмәгәндә яки аның аерым нигезләмәләрен төгәлләштерү максаты белән контрольлек объекты җитәкчесе актны алганнан соң җиде эш көне эчендә, актның аерылгысыз өлеше булган үз искәрмәләрен (каршылыкларын) эчке финанс контроле органына җибәрергә хокуклы, аларга контроль органы һәр каршылык (кисәтү) буенча бәяләмәне җиде эш көне эчендә бирергә тиеш.

4.11.Авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү буенча чараларның барышын контрольдә тота.

5. Эчке финанс аудитын үткәрү

5.1. Эчке финанс аудиты түбәндәге максатларда функциональ бәйсезлек нигезендә контроль (аудит) объектларына карата гамәлгә ашырыла:

- эчке финанс контроленең ышанычлылыгын бәяләү һәм аның нәтиҗәлелеген арттыру буенча тәкъдимнәр әзерләү;
- бюджет хисаплылыгының дөреслеген һәм бюджет исәбен алып бару тәртибенең Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бюджет исәбе методологиясенә һәм стандартларына туры килүен раслау;
- бюджет акчаларын файдалануның экономиялелеген һәм нәтиҗәлелеген арттыру буенча тәкъдимнәр әзерләү.

5.2.Эчке финанс аудитын үткәргәндә өлкә һәм өлкә милкеннән файдалануны регламентлаучы законнарның һәм башка норматив хокукый актларның үтәлешен, шулай ук бюджет (бухгалтер) исәбе һәм хисаплылык формасын һәм эчтәлеген билгели торган норматив хокукый актлар таләпләренең үтәлешен тикшерү гамәлгә ашырыла.

5.3.Эчке финанс контроленең ышанычлылыгын бәяләү һәм аның нәтиҗәлелеген арттыру буенча тәкъдимнәр әзерләү максатында контроль (аудит) субъекты түбәндәге мәсьәләләрне тикшерә:

- эчке финанс контролен гамәлгә ашыру тәртибен, формаларын, методларын һәм периодиклыгын билгели торган норматив хокукый актлар булу, аларның Россия Федерациясе Бюджет кодексы таләпләренә туры килүен тикшерү;
- календарь елга төзелгән һәм расланган контроль (аудит) субъекты тарафыннан план булу;
- планда каралган контроль чараларның тулы һәм үз вакытында үтәлеше;
- контроль чараларны оештыру һәм уздыру таләпләрен үтәү;
- үткәрелгән тикшерү чараларының рәсмиләштерелгән материалларының булуы;
- контроль чаралар нәтиҗәләре буенча актны рәсмиләштерүгә карата таләпләрне үтәү;
- контроль чаралар үткәрү мәсьәләләре буенча граждannар һәм оешмаларның мөрәҗәгатьләрен үз вакытында карау;

- контроль эшчәнлек турында хисап булу, анда контроль чаралар нәтиҗәләрен чагылдыруның дөреслеге һәм тулылыгы;
- программаларны, ярдәмче программаларны, чараларны үтәгәндә максатчан күрсәткечләрне анализлау;
- алдагы контроль чарасы тарафыннан ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү;
-эчке финанс контролен үткәрү һәм аның нәтиҗәләрен рәсмиләштерү өлешендә башка мәсьәләләр.
5.4.Бюджет хисаплылыгының дөреслеген һәм Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән бюджет исәпкә алу методологиясен һәм стандартларын бюджет исәбенә алып бару тәртибенең туры килүен раслау максатында түбәндәге мәсьәләләрне тикшерүне гамәлгә ашыра:
- бюджет төзү һәм үтәү, бюджет хисабы төзү һәм бюджет исәбен алып бару;
- бюджет (бухгалтерия) хисаплылыгын тикшерү, аның дөреслегенә, аны төзү һәм бирүнең үз вакытында булуына анализ ясау;
- дебитор һәм кредитор бурычларын анализлау, аны киметү һәм түләтү буенча тәкъдимнәр эшләү;
- бюджет исәбенең беренчел күрсәткечләрен анализлау;
- бюджет исәбендә һәм хисаплылыкта җитешсезлекләрне һәм хокук бозуларны ачыклау;
- бюджет исәбен алып бару өчен программа-техник комплекс булу;
- бюджет хисаплылыгының дөреслегенә аудит үткәрү һәм бюджет исәбен алып бару тәртибенең туры килүе өлешендә башка мәсьәләләр.
5.5.Икътисадый булуны арттыру һәм бюджет акчаларыннан файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру тәкъдимнәрен әзерләү максатында финанслар белән идарә итү буенча контроль (аудит) объектлары эшчәнлегенә анализ ясаганда һәм бәя биргәндә түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:
- бюджет акчаларыннан файдалануның нәтиҗәлелеген анализлау, финанс резервларын, шулай ук өстәмә финанс ресурсларын (эшчәнлекнең керем китерә торган акчаларыннан, максатчан программаларда катнашудан һ.б.) җәлеп итү юнәлешләрен ачыклау;
- проектлар һәм программаларның нәтиҗәләрнең билгеләнгән максатларга, нәтиҗәлелекнең планлаштырылган күрсәткечләренә туры килү-килмәвен тикшерү;
- бюджет йөкләмәләрен вакытында финанслау өчен кирәкле норматив хокукый актлар эшләүнең һәм кабул итүнең үз вакытында башкарылуын анализлау.
5.6. Уздырылган тикшерү нәтиҗәләре буенча контроль субъектының (аудит)вазыйфаи затлары тарафыннан эчке финанс аудиты нәтиҗәләре турында бәяләмә (алга
таба - нәтиҗә) төзелә, анда ачыкланган хокук бозуларны һәм җитешсезлекләрне бетерү,җыелган дәлилләр нигезендә эчке финанс контроленең нәтиҗәлелеген арттыру буенчатәкъдимнәр күрсәтелә.
5.7. Йомгак ясар алдыннан алынган дәлилләрнең ни дәрәҗәдә җитәрлек һәм тиешлебулуын бәяләргә тәкъдим ителә.

Дәлилләр фактларга нигезләнгән мәгълүмат ышандырырлык булса, җитәрлек дипсанала.
Әгәр мәгълүмат иң тулы һәм ышанычка лаек булса, ышанычлы дәлилләр дип санала.
Мәгълүмат күзәтүләрне һәм рекомендацияләрне расласа, төгәл дәлилләр булыптора.
Әгәр мәгълүмат контроль субъектына (аудит) үз максатларына ирешергә ярдәм итсә,файдалы дәлилләр дип санала.
Күрсәтмәләр ясалган нәтиҗәләрне һәм тәкъдимнәрне нигезләргә тиеш.
5.8. Бәяләмә ике нөсхәдә төзелә һәмул кереш, аналитик һәм йомгаклау өлешләреннәнторырга тиеш.
5.9. Бәяләмәне контроль субъектының (аудит) эш төркеме имзалый, ул контрольсубъекты (аудит) җитәкчесе белән килештерелә һәм тикшерүнең соңгы көненнән дә соңгакалмыйча имза салу өчен контроль (аудит) объектына җибәрелә.
6.0. Эчке финанс аудитын үткәрү нәтиҗәләре буенча контроль ачыкланган хокук бозуларны һәм җитешсезлекләрне бетерү, эчке финанс контроленең нәтиҗәлелеген арттыру буенча тәкъдимнәрне нәтиҗәле гамәлгә ашыруны тәэмин итүдән гыйбарәт һәм Җирлек башлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.